# МӘҖИТ ГАФУРИ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ "ХӘСРӘТ" КОНЦЕПТЫ

*Кәримова Р., КФУ, ф.ф.к.Хөснетдинов Д.Х.*

Хис-кичерешләр концептларын анализлау теге яки бу тел материалы ярдәмендә кешенең эчке дөньясын төзүдә аерым зур әһәмияткә ия.

Хәсрәт – рус теленә горе, печаль, скорбь дип тәрҗемә ителүче эмоциональ концепт. Хәсрәт сүзе гарәп теленнән кергән һәм кайгы, әрнү, хәсрәт дигәнне аңлата.

Татар халкының борынгыдан ук бик чыдам, түземле, бәла-казаларны уртаклаша, күтәрә белүче милләт икәнен беләбез. Әлеге сыйфатларга дәлилләр мисалларда да чагылыш таба:

*Соңгы вакытларда Закирның анасы да безгә бик җыш килеп, кайгы-хәсрәтләрне уртаклашып китә торган булды* [Гафури 2007: 369].

*Һәркем үзенең кайгы-хәсрәтене шуның белән уртаклашадыр* [Гафури 2007: 212].

Тик, кызганычка каршы, кешеләр һәрвакытта да мәрхәмәтле булмыйлар шул, алар белән кайчакта кайгы уртаклашудан бигрәк, кызыксыну хисе идарә итә.

*... Хәсрәтләрен уртаклашалар, шунлыктан безнең өйдә дә борынгы кебек тыныч, матур тормыш югалган кебек булды* [Гафури 2007: 347].

Диндә дә мөселман кешесе сабыр, түземле булырга тиеш итеп каралган, чөнки хәтта пәйгамбәрләр дә кайгы-хәсрәт күргән. Әлеге хәсрәтләрне лаеклы рәвештә уздыра белергә кирәк.

*Кайгы-хәсрәт бер безнең генә баштан үтмәгән, аны пәйгамбәрләр дә күргән* [Гафури 2007: 252].

Әлеге сүзнең фразеологик берәмлекләр компоненты буларак кулланылуы да гадәти күренеш. Әлеге мисалларда түбәндәге фразеологизмнар очрады: хәсрәткә төшү – кайгыга бату, офтану мәгънәсен; хәсрәт чигү – хәсрәтләнү, кайгыру, көенү мәгънәсен белдерә.

*Бик авыр хәсрәткә төштек* [Гафури 2007: 389].

*Уйламаган хәсрәтләргә килеп төштек* [Гафури 2007: 325].

Хәсрәт лексемасы, һичшиксез, кешенең эчке тирән кичерешләре белән бәйләнгән, әмма ул шулай ук кичерелгән хисләрнең башкаларга да күренгән тышкы чагылышлары белән бәйләнә.

*Бәлки үзләренең хәсрәтләрен тик торулары һәм йөзләренә чыккан күңелсезлекләре белән генә белдереләләр иде* [Гафури 2007: 299].

Хәсрәт яңарырга, онытылырга, алып ташланырга, иске кием кебек салынып ташланырга, куелып торырга, йөзне чокырлатырга, эчне пошырырга, күңелне ачуландырырга, моңландырырга, күңелдә нәфрәт тудырырга, артырга, хәтта җиргә сыймаска мөмкин, ул чакта инде кеше күкләргә аша.

*Тагын нинди хәсрәтләрне яңартып утырасыз?* [Гафури 2007: 325].

Хәсрәт – авыр, чиксез, зур, көчле, ышанып булмаслык, уйламаган булырга мөмкин:

*Бик авыр хәсрәткә төштек* [Гафури 2007: 389].

Аталар белән балалар арасындагы мөнәсәбәтләр гел уңай гына бармый. Балалар үзләренчә, яңача фикер йөртә һәм шуның белән ата-ананы хәсрәткә салырга да мөмкиннәр.

- *Әти, сез, зинһар, минем өчен урынсызга хәсрәтләнмәңез* [Гафури 2007: 195].

Күп очракта безнең нәрсә өчен булса да хәсрәтләнүләр юкка гына була, без үзебезне генә бетерәбез. Тик милләт өчен хәсрәтләнү, борчылу, нидер эшләргә тырышу азмы-күпме файда китерә.

*Безнең кайгы-хәсрәтемездән милләткә бер тиенлек файда булмаса да, үземездән соңгыларың коры кайгы-хәсрәт белән тормый,... милләткә файда китерәчәкләренә сәбәпче булырмыз өмидендә идек* [Гафури 2007: 200].

Хәсрәтле чакларда ашап-эчеп, йоклап булмый, елата. Тик кайбер очракларда ашарыңа ризык, аш булу барлык кайгы-хәсрәтләрне дә бетерә.

*Минем ниһаятьсез хәсрәт эчендә ашамый-эчми, юньле йокламый утырганымны күреп кызганган була* [Гафури 2007: 227]...

Гафури хәсрәтне ташып түгелергә торган күз яшенә, дулкыннарга охшатып та сурәтли.

*Куәтле дулкыннарның чүпләрне яр читләренә чыгарып ташлаганы кеби, ... кайгы вә хәсрәтләре мине дә үзеннән чыгарып ташлавына ышанган идем* [Гафури 2007: 229].

Кеше өчен иң хәсрәтле вакыйга ул – үлем-җитем булу. Тик кайбер вакытта хәсрәтнең шундый авыры килә, үлем булмаса да, “өй эче хәсрәткә әйләнә”. Бу очракта без җансыз предмет булган өйгә дә хисләр хас булуын күрәбез.

*Шулай итеп, безнең өй эче, яңа гына үлек чыккан кебек, хәсрәткә әйләнде* [Гафури 2007: 301].

Шунысы кызык: хәсрәт лексемасы татар телендә тиргәлүчегә мөрәҗәгать итү буларак та кулланыла: *И хәсрәт, югал күземнән*! “Татар теленең аңлатмалы сүзлеге”ндә “хәсрәт” дип юкны кайгыртып, юкка көенеп йөргән кешегә карата ачулану катыш әйтелә торган сүз итеп бирелә.

*Хәмидә әби ... бу ике хәсрәт өстенә карап, һичбер сүзсез тик тора иде* [Гафури 2007: 325].

Димәк, матур әдәбият әсәрләрендә дә хәсрәт кешелеккә зур зыян салучы актив хәрәкәтчән көч буларак күзаллана.

Әдәбият

Гафури Мәҗит. Сайланма әсәрләр. – Казан: Тат. Респ.“Хәтер” нәшр., 2007. – 479 б.